«ПЫЧАК» ЛЕКСЕМАСЫНА ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИК ТАСВИРЛАМА

*Хөснуллина Г., КФУ, ФСИның тәрҗемә һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге*

*Җитәкче - филол. фән. канд., доц. Нурмөхәммәтова Р.С.*

Татар халкы бервакытта да кул кушырып утырмаган, ул һәрвакыт нәрсә белән булса да шөгыльләнгән, шуңа күрә татар кешесе тормыш-көнкүреше өчен кирәкле савыт-сабаларны, йорт кирәк-яракларын да үзләре җитештергән.

Ашау-эчү хәзерләү кеше тормышында төп рольне уйный, ризык әзерләү ысуллары барлык халыкларда да гаять төрле. Бу процессны савыт-саба, төрле кораллардан башка күз алдына да китереп булмый. Бүгенге көндә савыт-сабалар төрлелеге үзенә игътибарны ныграк җәлеп итә. Ашамлыкларны (ит, балык, котлет, яшелчәләр) әзерләү ысуллары кухня кирәк-яраклары үзгәрүгә дә сәбәп булган. Шуңа бәйле рәвештә казаннар, чуен-чүлмәкләр, шулай ук агачтан эшләнгән кухня кирәк-ярагы икенче планга күчеп, беренче урынга металлдан эшләнгән савыт-сабалар чыккан. Әлеге предметларның атамаларын күзәтү дә кызыклы гына нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Аш әзерләү өчен кулланыла торган савыт-саба атамаларыннан *казан, киле, коштабак, куна такта, кәстрүл, пычак, таба, табак,табагач, тукмак, тәгәч, түкмән, соскыч, уклау, шава, чуен, чүлмәк, чүмеч* һ.б. атарга була. Ә без исә шулар арасыннан бары тик берсенә генә тукталабыз. Бу – “пычак” лексемасы.

**Пычак** – безнең тормышыбызда көн дә кулланыла торган предмет. Аш өендә ул иң мөһим предметлардан санала. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә аңа түбәндәге билгеләмә бирелә: “пычак – кисү, турау өчен бер башына сап куелган, бер ягына үткен яссы металл кисәге” [ТТАС 2005: 435]. Р.Әхмәтьянов сүзне гомумтөркиләрнең пычак // бычак, ә борынгы төркиләрдә быч-чак “кисә торган нәрсә” дигәннән килеп чыккан дип билгели [ТТКТЭС 2001: 165]. Пычакның төп функциясе кисү икәне аңлашыла. Гомумән, *бычу* фигыле борынгы төрки телдә “ƀïč (быч)” тамырыннан ясалып, “резать, рубить, косить” мәгънәсен белдерә [ДТС 1969: 104]. Әлеге тамырдан ясалып, *пычак* сүзе белән уртаклыгы булган башка сүзләр дә бар. Мәсәлән, “пычкы” лексемасы. Борынгы төрки сүзлектә аңа түбәндәге аңлатма бирелгән: “ƀïčyu – приспособление для

резания, нож” [ДТС 1969: 105]. Аңлатмалы сүзлектә: “агач, металл, таш кисү өчен бер ягы тешле, озынча яссы корыч кисәгеннән гыйбарәт корал” дип теркәлә [ТТАС 2005: 435]. Димәк, әлеге лексемалар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торалар, бары тик кулланылу өлкәләре белән генә аерылалар.

Фразеологик сүзлектә савыт-саба, кухня кирәк-яраклары атамалары арасында иң күп кулланылганы да – “*пычак”* лексемасы. Башкалары алай ук еш очрамый. Мәсәлән: *аркадан пычак кадау* – ике йөзле; *пычак кайрау* – кемгәдер астыртын янау, һөҗүм итәргә булдыра алмаган дошманның тыныч яктан астыртын хыянәтчел һөҗүме; *ике йөзле пычак* – ике йөзле; *пычакка пычак килү* – берсен икенчесе һәлак итү дәрәҗәсендәге капма-каршы дошманлык турында; *пычаксыз сую* – кемне дә булса бик авыр хәлгә кую, һәлак итү; *тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән* – тупас кеше, дөнья күрмәгән кеше [ТТФС 1990: 55] һ.б. Шулай ук мәкальләрдә дә *пычак* сүзе еш очрый. Мәсәлән, *“баланың кулыннан пычак алсаң, алмашына таяк бир”*, *“балага пычак бирмәсәң – бер елар, бирсәң – ике елар”*, *“яхшы сүз белән елан өненнән чыгар, яман сүз белән пычак кынынnan чыгар”*, “*сүз бирергә җитез булма, сүз бирсәң, чыны белән бир, пычак бирсәң, кыны белән”*, *“утка пычак тыкма”, “беткә пычак суырма”* (кечкенә нәрсәгә корал күтәрмә), *“арык үгезгә пычак юк”* (арык булганга ите өчен суярга кирәк тапмыйлар), *“буынсыз җиргә пычак салма”* (эшкә ашмый торган боерык биреп яки сүз үтми торган урында урынсызга сүз кузгатып маташуларга карата әйтелә), *“кырык үгезгә бер пычак җитә”* (сугышта дошманның күплегеннән куркырга кирәкми, дигәнгә мисал йөзеннән әйтелә), *“өч нәрсә кешене картайтыр: йөремсез ат, үтмәс пычак, яман хатын”* [ТХМ 2000: 6, 8, 18, 26, 48] һ.б.

Пычак лексемасы әдәби әсәрләрдә дә еш очрый. *Фәрихә, бәрәңге котлетларын пычак очы белән әйләндереп маташкан килеш, Әхмәткә карап елмайды да, эчке бүлмәгә ымлап: - Кунаклар бар бит, - диде* (Ш.Камал). *Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә, тәлинкә, чәнечке-пычак, рюмкалар чыңлавы ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый*

(Ә.Еники). *Пычак астына барып кергән яшь атның өзгәләнеп кешнәвенә карт атлар кушылып ярсыйлар, кычкырыналар...* (М.Мәһдиев). *Озынның ач, комсыз карашы Һадия абыстайның ... билбавыннан пычак тартып чыгарды...* (М.Кәбиров). Бу мисалларда *пычак* үзенең туры мәгънәсендә, ягъни – кисә торган корал буларак кулланылган.

Әдипләр *пычак* сүзе кергән фразеологизмнарны да әсәр тукымасына уңышлы кертеп җибәрәләр. — *Әй, малайлар... Куркытма! Әй, пычак кергере!.. Кая сыерымны алып барасың?* (Г.Исхакый). Әлеге мисалда исә, *“пычагым (пычак) кергере”* – суелгыры, пычакка кадалгыры, эченә пычак кереп үлгере, янәсе, дигәнгә туры килә.

*«Ирең инженер булсын. Шуның хезмәт хакына яшәргә язсын», дип теләк теләгән, каргаган, — ди бит бер хатын күршесе белән пычакка-пычак килеп талашканда* (Р.Мөхәммәдиев). Монда *“пычакка-пычак килү”* – берсен икенчесе һәлак итешү дәрәҗәсендәге капма-каршы дошманлык дигәнне аңлата.

Татарстан районнарында һәм башка республикаларда яшәүче барлык татарларның телендә бу предметның *пычак* дигән атамасы бар. Мишәр диалектының ц-лаштыручы сөйләшләрендә *пыцак* (Буа районы), с-лаштырып сөйләшүче Дөбъяз сөйләшендә *пысак* (Яшел Үзән районы) вариантлары йөри.

Вакыт татар кешесенең аш-су өенә (кухнясына) нинди генә заманча, модалы савыт-саба алып “кермәсен”, татарлар, элеккеге традицияләренә тугры калып, инде сыналган, меңнәрчә еллар игелекле хезмәт иткән кирәк-яракларны куллануларын дәвам итәләр. Пычак әнә шундый коралларның берсе, аны кулланмаган бер генә көн дә юк, барлык ризыклар да аның аша “үтә”, нинди генә рәвешләр алса да, аның исеме һаман шул ук. Нәкь менә шуңа да ул телдә, халык авыз иҗатында, әдәби әсәрләрдә актив.

Савыт-саба атамаларының лингвокультурологик асылын ачу татар милли дөнья тел картинасын тулырак күзаллау өчен гаять мөһим.

Әдәбият

http://kitap.net.ru

ДТС – Древнетюркский словарь. – Ленинград: Наука, 1969. – 676 с.

Җамалетдинов, Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.

Исәнбәт, Н. Отканга мәкаль, тапкырга табышмак. – Яр Чаллы: Идел-йорт, 2000. – 92 б.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты. 2005. – 849 б.

ТТКТЭС – Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

ТТФС – Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. – 365 б.